# EMINENT PHILOSOPHER AND ART CRITIC (90 YEARS SINCE THE BIRTH OF KAZBEK GIZZATOV)

**Ruzal Abdullazyanovich Yusupov**,
Kazan Federal University,
2 Tatarstan Str., Kazan, 420021, Russia,
dilara-47@mail.ru.



**GIZZATOV KAZBEK TAZIEVICH** (1925-2014) was a philosopher, Doctor of Philosophy (1979), Professor (1980) and Honoured Scientist of TASSR (1985). In 1943-1954 he was in the Soviet army, a veteran of the Great Patriotic War. He was awarded the Order of the Patriotic War, Second Class, and medals. After graduating from the University of Kazan (1960) he worked for the journal *Tatarstan kommunisty* (*'Communist of Tataria'*), and from 1965 he was a head of the Department of Marxism-Leninism of the Kazan Conservatory. From 1977 he was a head of the Philosophy Department of Kazan Financial and Economic Institute and in 1987-1997 he was a head of the Department of Philosophy of the Kazan University of Culture and Art. He worked on the problems of national relations, national ideology, the dialectic of the national and universal in art, the artistic method and the theory of culture. He is an author of scripts, films and plays, books on philosophy and aesthetics in the Tatar language.

**ГЫЙЗЗӘТОВ КАЗБЕК ТАҖИ улы** (1925-2013) – философ, философия фәннәре докторы (1979), профессор (1980), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1985). 1943-1954 елларда Совет армиясендә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнгән. Казан университетын тәмамлагач (1960), «Татарстан коммунисты» журналы редакциясендә эшли, 1965 елдан Казан консерваториясендә марксизм-ленинизм кафедрасы мөдире. 1977 елдан Казан финанс-икътисад институтында философия кафедрасы мөдире. 1987-1997 елларда Казан мәдәният һәм сәнгать университетында философия кафедрасы мөдире.

Хезмәтләре милләтара мөнәсәбәтләр, милли идеология, сәнгатьтә миллилек һәм гомумкешелек кыйммәтләре диалектикасы, фәлсәфә һәм мәдәният тәгълиматы мәсьәләләренә карый. Фильм сценарийлары һәм пьесалар, философия һәм эстетика фәннәреннән татар телендә дәреслекләр авторы.

**ГИЗЗАТОВ КАЗБЕК ТАЗИЕВИЧ** (1925-2014) – философ, доктор философских наук (1979), профессор (1980), заслуженный деятель науки ТАССР (1985). В 1943-1954 гг. в рядах Советской армии, участник Великой Отечественной войны. Награжден орденом Отечественной войны 2 степени, медалями. После окончания Казанского университета (1960) работал в редакции журнала «Коммунист Татарии», с 1965 года заведующий кафедрой марксизма-ленинизма Казанской консерватории. С 1977 года заведующий кафедрой философии Казанского финансово-экономического института, с 1987 года в Казанском университете культуры и искусства (до 1997 года заведующий кафедрой философии).

Труды по проблемам национальных отношений, национальной идеологии, диалектике национального и общечеловеческого в искусстве, художественного метода и теории культуры. Автор сценариев фильмов и пьес, учебников по философии и эстетике на татарском языке.

Summarizing many worthy personality traits of Kazbek Gizzatov, Honoured Worker of Science of the Republic of Tatarstan, Laureate of Award of the Tatarstan Academy of Sciences named after Sh. Mardzhany and winner of other honorary awards, we can say that he was a man of great faith, astounding efficiency, straightforwardness, courage and he was also a fighter for justice. He inherited these traits from his father and grandfather. His grandfather Kalimulla was from Agryzsky District and he was one of the men who believe in justice, bravery, resoluteness and courage. Kazbek Gizzatov grew up without his father Tazi Gizzat, who experienced all the bitterness of life, and taught himself to read and write. Thanks to his infinite diligence Tazi Gizzat became a prominent Tatar playwright, director, actor, and great public figure. He was a beacon for his son all his life. Inheriting the lamp of his father, Kazbek Gizzatov tried to continue his selfless work in the field of Tatar art and to be faithful to it, and he indeed became a great personality, who enriched his father's spiritual heritage.

Kazbek Gizzatov's youth occurred at the most difficult time for the country – the Great Patriotic War. In January 1943, when he was less than 18 years old and studying in the 10$^{th}$ grade at one of Kazan schools, he was drafted into the Red Army. When he finished the field artillery school in Leningrad, he was sent to the front. Even the death on the battlefield of his 19-year-old brother Uzbek Gizzatov, who was burned in the tank he had commanded, could not break the will of Kazbek.

And when even the war was over, officer Kazbek Gizzatov was not released from the army. He served for 10 years in various military districts (the last place was Sahalin). Only in January 1955 was he discharged from the army at the request of Gumar Bashirov, the Chairman of the Writers' Union of Tatarstan and the deputy of the Supreme Council of the USSR to the Soviet Defence Minister Marshal Bulganin. The reason for this request was that the father of Kazbek Tazi Gizzat was on his deathbed.

Kazbek was with his father for the last two months of his father's life. During conversations he realized that his father, playwright Tazi Gizzat, was a great personality. He felt deeply that his father's life had been spent at full capacity, and that he had made a huge contribution to the development of Tatar culture and dramatic art. Kazbek, who had spent all his youth serving in the army, firmly decided to follow in the footsteps of his father and to devote his life to Tatar culture.

After his father's death Kazbek carefully studied his manuscripts and put in order his personal archive, which contains different versions of numerous plays, journalistic articles, letters and other materials. He learned about the dramatic events of the life of his father which had happened in his absence. When he was in the army, he was not informed about the events taking place in Kazan. Kazbek felt guilty for not being there when his father experienced the difficult moments of his life. As a result, an officer in the reserve, who had intended to enter the Institute of Aviation and the Institute of Chemical Technology (he had earlier received a primary military-technical education), decided to continue his father's business.

Thus the future of Kazbek Gizzatov was determined. He entered the Department of Tatar Language and Literature of the History and Philology Faculty of the Kazan State University.

Having had the experience of a harsh life and having chosen the principle of life with a sense of mindfulness and consciousness, Kazbek gave himself to achieving a higher humanitarian education. He was an excellent student and received an honorary scholarship. He had already had a craving for research activities in his student days, and he actively participated in public life. Student Gizzatov, who had only had to deal with a gun and cannon, selected the theme "National characteristics in literature" as his main scientific direction.

After his graduation, Kazbek stayed in the graduate school in philosophy under the guidance of an outstanding scientist V.I.Abdrakhmanov. And very soon he defended his PhD thesis on "The Issue of national art forms". He then devoted the rest of his life to the training of students in higher educational institutions and to very active and fruitful research work in the fields of philosophy, aesthetics, sociology, and creative writing.

K.T.Gizzatov's book on national art with rich content was published twice [1; 2]. In 1978, he successfully defended his doctoral dissertation on this subject at the Council of Moscow University and became the first Doctor of Aesthetics among Tatars.

The principles, objectivity and straightforwardness of Professor K.T.Gizzatov are reflected in his scientific papers. In his work *National ideology* published in two volumes in Russian in Moscow, and *Philosophy* and *Aesthetics* and other works published in Tatar in Kazan, K.T.Gizzatov explained many of the problems of philosophy and aesthetics in a new way, expressed opinions on the issues, and if necessary, confidently engaged in polemics with respected scientists to defend the truth.

In his two-volume work on philosophy in addition to traditional topics, Professor K.T.Gizzatov fully and objectively highlighted the problems of "Muslims' Eastern philosophy in the Middle Ages", "Tatar Religious philosophy of the 19$^{th}$ century", "The issue of man in philosophy," "The issue of life and death in philosophy", "Culture and civilization", and "Process of globalization in society".

The work *Aesthetics* referred to the aesthetics of Ancient Egypt, the aesthetic outlook of the Arab-Persian and Turkic peoples, the aesthetics of the Tatars in the late 19th to early 20th centuries, the nationality of the art, the method of art as a system and other relevant and important issues.

The release of K.T.Gizzatov's books *Philosophy* and *Aesthetics* was a great event in the social life of the Tatars. Only competent and highly-educated scientists with good knowledge of both Tatar and Russian were able to produce such huge scientific work in Tatar on complex subjects. This enormous work was usually only carried out by scientific research institutes.

The national idea is a serious problem and its different aspects are considered in the scientific works of Professor K.T.Gizzatov. In his great work *National ideology*, published in Moscow in Russian in two volumes, K.T.Gizzatov explained concepts of a "national idea" and "national ideology", with particular relevance to contemporary issues and based on realistic reflection. The objective coverage of this important issue given by the Professor in connection with modernity and according to the realities gives us the ability to correctly perceive complex and intricate social environments.

According to K.T.Gizzatov, the national idea is not a set of specific qualities of a nation given at birth and forever (such way of thinking would belong to metaphysics). The national idea is the problem which must be solved in each particular historical period for each nation. For example, in the modern world the national idea for the Tatars is the task of preserving and developing their native language and culture and the idea itself.

Professor Kazbek Gizzatov, being a sensible and broad-minded man and having analysed the complicated situation in Russia, revealed the reasons for the economic and social difficulties of the country and showed clearly the method of development for Russia to be on a par with other developed countries. He had the following thoughts about the future of the Russian Federation: there were positive and negative aspects of socialism. For example, in our time, the principles of totalitarianism are not popular among people, among the younger generation in particular, especially the repressions of the 1930s. Besides, those people who have seen and been aware of the achievements of socialism are passing away due to their age, and the rest of them are not able to actively participate in building the future of society. Therefore, the younger and middle generations of Russia can only see the negative side of socialism.

Those pseudo-theorists, who are on the side of false Democrats, are only able to lead people directly to wild capitalism. It is evident that if during the Soviet period our country was considered to be the second most powerful state in the world according to the opinion of the most respected international organizations (the first place was taken by the USA), now Russia, having been updated after perestroika, which lasted for a quarter of a century, has to settle for one of the last places. And people have had enough of all the "amazing" qualities of capitalism, praised by democrats. Therefore, when it comes to the future, politicians cannot directly promote a return to the capitalist system.

Keeping in mind the difficult situation in the country and some separation of national consciousness, K.T.Gizzatov considered it appropriate to define the future of Russian society according to civilization measures. In his opinion, at the present stage the appropriate primary goal of the country would be the achievement of the values of civilization. He believed that only the society which chose this direction would have its national ideology. This society, like others, would include the following branches: economic production, social sphere, culture (tradition, education, science, art, etc.), and the legal sphere. Modern Russia is far behind the civilized countries in all sectors. Therefore, based on the experience of advanced countries (however, regardless of the specifics of Russia), it is necessary to rebuild the country according to their example. Examples of such achievements already exist; they are relatively advanced and meet modern requirements. For instance, Germany, France, Japan and China could be models of production for our future society based on new advanced technologies. In the social sphere, Scandinavian countries might also be appropriate (Sweden, Norway and Finland), as well as Belgium and the Netherlands; in the legal sphere the experience of England may serve as an example; and in education - the achievements of the former USSR. So Russia could build its future, including the national ideology, based on current civilizations.

The 40 years of K.T.Gizzatov's pedagogical activity can be a good example for many teachers. He could be characterized as a highly-cultured, po-

lite and modest man in his communications with colleagues, and in training and educating the students.

He was one of the first lecturers in Kazan universities who began to give lectures on philosophy and aesthetics in Tatar. He explained the difficult material in a clear and plain language. Professor K.T.Gizzatov was a friendly man with a great soul, and he was always ready to help everybody at any moment. He is warmly remembered by thousands of his students.

There is a saying – a talented person is talented in everything. This statement also fits the protagonist of our work. Professor K.T.Gizzatov was a great scientist and an outstanding teacher who also managed to be outstanding in literature. It is apparent that the creative talent of his father was passed on to him. He wrote the screenplay for the TV serial film based on the trilogy of Tazi Gizzat *Torrents of Spring*. This film was shown on screens in 1980. In the 1990s he wrote the script in Russian for eight serial television films *In the August of '91*. It was published as a separate book in 1997.

Speaking about the personal qualities of Kazbek Gizzatov, we must mention his great respect for the memory of his father and for his work. He has done a lot to preserve his father's artistic heritage and bring it to the modern reader. In honour of the 80th anniversary of the birth of Tazi Gizzat he published his novels in 4 volumes. In 2009, thanks to his efforts, the five-volume edition was published. He also produced a large work named *Tazi Gizzat. Thoughts. Memories. Letters. Debates* [6]. He wrote many articles about the rich oeuvre of his father.

Without moving away from the valiant way of his father, Kazbek Gizzatov himself set the example for his children. He left worthy successors. His daughters Guzel and Gulnaz cherish and increase the spiritual heritage of their father and grandfather. Guzel Gizzatova heads the Department of English in one of Kazan universities. She successfully defended her doctoral thesis on the communication of meaning of the Tatar phraseological units through stylistic means of English, and became a Professor. Despite the fact that she is an expert in English, Guzel is actively engaged in the issues related to the Tatar language. Her research paper on the stylistic means of the Tatar language was recently highly appreciated by foreign scientists at the Sorbonne. Thus continues the decent work of the noble Gizzatovs dedicated to the development of culture, education and science.

It has recently been 90 years since the birth of Kazbek Gizzatov (he passed away about a year ago). Numerous colleagues and students who knew and respected this great man honoured his memory. The selfless lives of the noble father and son – Tazi and Kazbek Gizzatovs, devoted to the development of Tatar spirituality, will remain in the hearts of thousands of people.

**References**


1. *Gyyzzätov K.T.* Näfasät (Berenche kitap). Kazan: Mägarif, 2004. 495 b. (in Tatar)
2. *Gyyzzätov K.T.* Näfasät (Ikenche kitap). Kazan: Mägarif, 2006. 480 b. (in Tatar)
3. *Gizzatov K.T.* Natsional'naya ideologiya. M.: "Soyuz", 1999. 199 s. (in Russian)
4. *Gyyzzätov K.T.* Filosofiya (Berenche kitap). Kazan: Mägarif, 2002. 447 b. (in Tatar)
5. *Gyyzzätov K.T.* Filosofiya (Ikenche kitap). Kazan:, Mägarif, 2003. 407b. (in Tatar)
6. *Gyyzzätov K.* Taži Gyyzzät. Kazan: Master Layn, 2000. 512 b. (in Tatar)


---

# КҮРЕНЕКЛЕ ФИЛОСОФ ҺӘМ СӘНГАТЬ ГАЛИМЕ (КАЗБЕК ГЫЙЗЗӘТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ)


**Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420021, Казан ш., Татарстан ур., 2 нче йорт,
dilara-47@mail.ru.



Бу язмада сүз философия фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан фәннәр академиясенең Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты һәм башка мактаулы исемнәр иясе Казбек Таҗи (Таҗетдин) улы Гыйззәтов турында булыр.


Казбек Гыйззәтовның күп төрле күркәм сыйфатларын гомумиләштереп, болай дип әйтергә мөмкин: ул зур ихтыяр көченә ия, искиткеч эшлекле, туры сүзле, гаделлек өчен көрәшүче, кыю кеше иде. Холкының бу үзенчәлекләре аңа бабасыннан һәм атасыннан

килә. Бабасы Кәлимулла Әгерҗе якларындагы гаделлеккә табынучы, кыю йөрәкле, тәвәккәл, гаярь ирләрнең берсе булган. Яшьтән атасыз калып, тормышның бөтен ачысын татып, укырга-язарга үзлегеннән өйрәнеп, чиксез тырышлыгы аркасында, татар халкының күренекле драматургы, режиссеры, актеры, зур җәмәгать эшлеклесенә әверелгән әтисе Таҗи Гыйззәт (Таҗетдин Гыйззәтов) Казбек Гыйззәтов өчен гомере буена якты маяк була. Ул, атасыннан үрнәк алып, аның татар сәнгате өлкәсендәге фидакарь эшләрен дәвам иттерергә, аңа турылыклы булырга тырышып яши, һәм ул, чыннан да, атасына лаеклы, аның рухи мирасын баеткан олуг шәхес.

Казбек Гыйззәтовның яшьлеге Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Ул, 1943 елның гыйнварында Казан мәктәпләренең берсендә унынчы класста укып йөргәндә, 18 яше дә тулмаган килеш, Кызыл армия сафларына алына. Ленинградта хәрби артиллерия училищесын тәмамлагач, фронтка җибәрелә. Дәһшәтле сугыш кырында 19 яшьлек абыйсы Үзбәк Гыйззәтовның үзе командалык иткән танк эчендә янып һәлак булуы егетнең рухын сындыра алмый.

Сугыш тәмамлангач та, офицер Казбекны армиядән җибәрмиләр. Ул төрле хәрби округларда (соңгы хезмәт урыны Сахалинда була) 10 ел хезмәт итә. Аны, Татарстан язучылар союзы рәисе, СССР Югары Советы депутаты Гомәр Бәшировның СССР Оборона министры маршал Булганинга үтенече нәтиҗәсендә, 1955 елның гыйнварында гына армиядән азат итәләр. Бу үтенечнең сәбәбе исә шул була: Казбекның әтисе Таҗи Гыйззәт ул чакта үлем түшәгендә ята.

Казбек, әтисе үләр алдыннан, ике ай буе аның янында була. Әтисе белән шул көннәрдәге әңгәмәләрендә ул драматург Таҗи Гыйззәтнең нинди күркәм шәхес икәнлегенә төшенә, аның фидакарьлек белән үткән тормыш юлын, татар мәдәнияте, театр сәнгате үсешенә керткән гаять зур өлешен йөрәге аша үткәрә, һәм яшьлек еллары армия сафларында узган Казбек гомерен әтисе хезмәт иткән өлкәгә – татар мәдәниятенә багышларга, әтисе юлын дәвам иттерергә дигән ныклы фикергә килә.

Әтисе үлгәннән соң, Казбек аның кульязмаларын җентекләп өйрәнә, күп санлы пьесаларының төрле вариантлары, публицистик мәкаләләре, хатлары һәм башка материаллары тупланган шәхси архивын тәртипкә сала. Шушы вакытта аңа туган якларыннан аерылып торган арада әтисе тормышында булган драматик сәхифәләр ачыла. Армиядә чагында Казанда булган хәлләр турында аңа хәбәр итеп тормаганнар. Казбек, әтисенә авыр вакытларда өйдә була алмавы өчен, үзен аның алдында гаепле итеп тоя. Нәтиҗәдә, авиация яки химия-технология институтларының берсендә укырга дип уйлап йөргән запастагы офицер (чөнки ул урта хәрби-техник белемле була) әтисенең гомере буе башкарган эшен дәвам итәргә дигән карарга килә.

Шулай итеп, Казбек Гыйззәтовның киләчәк язмышы хәл ителә. Ул Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.

Кырыс тормыш тәҗрибәсе алып өлгергән Казбек, бөтен көч-куәтен биреп, югары гуманитар белем алырга керешә. Ул, «бишле»гә генә укып, исемле стипендия ала, студент елларында ук фәнни эшләргә тартыла, иҗтимагый тормышта актив катнаша. Моңа кадәр пушка, автомат белән эш иткән студент Гыйззәтов «Әдәбиятта милли үзенчәлекләр» дигән теманы фәнни эшенең төп юнәлеше итеп сайлап ала.

Казбек, университетта укуын тәмамлагач, күренекле галим М.И.Абдрахманов җитәкчелегендә фәлсәфә буенча аспирантурада калдырыла. Һәм ул тиздән «Сәнгатьнең милли формалары мәсьәләсе» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Казбек Гыйззәтовның шуннан соңгы гомере югары уку йортларында студентлар укытуга, фәлсәфә, эстетика, социология һәм әдәбият белеме өлкәләрендә гаять актив, нәтиҗәле гыйльми эшкә һәм әдәби иҗатка багышлана.

К.Т.Гыйззәтовның милли сәнгать турында бай эчтәлекле китабы ике тапкыр дөнья күрә [1; 2]. 1978 елда ул шушы тема буенча Мәскәү университеты советында уңышлы рәвештә докторлык диссертациясе яклап, татарлардан эстетика өлкәсендә беренче фән докторы була.

Профессор Казбек Гыйззәтовның принципиальлек, объективлык һәм туры сүзлелек сыйфатлары аның фәнни хезмәтләрендә дә чагылыш таба. Мәскәүдә рус телендә чыгарылган ике томлык «Национальная идеология» [3], Казанда татар телендә нәшер ителгән «Философия» [4; 5], «Нәфасәт» дигән китапларында һәм башка хезмәтләрендә К.Т.Гыйззәтов фәлсәфә, эстетика фәннәрендәге күп мәсьәләләрне яңача аңлата, четерекле проблемалар буенча үз

фикерен әйтә, кирәк булганда, моңа кадәр абруйлы дип саналган галимнәр белән бәхәскә кереп, кыю рәвештә дөреслекне яклый.

Ике китаптан торган фәлсәфә дәреслегендә профессор К.Т.Гыйззәтов, дәреслекләрдәге традицион темалардан тыш, «Урта гасырлардагы Көнчыгыш мөселман философиясе», «XIX гасыр татар дини философиясе», «Философиядә кеше проблемасы», «Философиядә яшәү һәм үлем проблемасы», «Мәдәният һәм цивилизация», «Җәмгыятьтә глобальләшү процессы» мәсьәләләре турында яза һәм бу өлкәләрдәге проблемаларны тулы һәм объектив яктырта.

«Нәфасәт» (эстетика) дәреслегендә исә «Борынгы Мисыр нәфасәте», «Гарәп-фарсы һәм төрки халыкларның нәфасәти карашлары», «XIX гасыр азагы – XX гасырның беренче яртысында татар нәфасәте», «Сәнгатьнең миллилеге», «Система буларак сәнгать методы» һәм башка көн үзәгендә торган әһәмиятле темалар һәм проблемалар бәян ителә.

Казбек Гыйззәтовның «Философия» һәм «Нәфасәт» китаплары дөньяга чыгу татарларның иҗтимагый тормышында олы вакыйга була. Катлаулы гыйльми темаларга татарча шул кадәр зур күләмле фәнни хезмәтләр язып бастыру – рус телен дә, татар телен дә бик яхшы белгән зур эрудицияле, олпат галимнәр кулыннан гына килерлек эш. Мондый зур эшне, гадәттә, академик тикшеренү институтлары гына башкара.

Профессор К.Т.Гыйззәтовның төрле юнәлешле гыйльми эшчәнлегендә яктыртылган бер җитди проблема ул – милли идея проблемасы. К. Гыйззәтов Мәскәүдә рус телендә басылып чыккан «Национальная идеология» («Милли идеология») дигән ике томлы зур хезмәтендә хәзерге чор өчен аеруча актуаль булган «милли идея», «милли идеология» төшенчәләрен реалистик фикер йөртү җирлегендә аңлата, һәм монда галимнең бу әһәмиятле мәсьәләне, бүгенге чынбарлык белән бәйләп, объектив яктыртуы хәзерге катлаулы социаль хәлләрне реаль итеп, дөрес күзалларга мөмкинлек бирә.

Милли идея, К.Т.Гыйззәтов карашынча, тегe яки бу халыкка тумыштан һәм мәңгегә бирелгән сыйфатлар җыелмасы түгел (болай фикерләү метафизика булыр иде). Милли идея ул – һәр конкрет тарихи чорда һәрбер халык өчен хәл ителергә тиешле проблема. Мәсәлән, татарлар өчен бүгенге чорда милли идея халкыбызның телен, мәдәниятен һәм шуның белән бергә аның үзен саклап калу һәм үстерү бурычыннан гыйбарәт.

Профессор К.Гыйззәтов, киң масштаблы, реаль фикер йөртүче галим буларак, Россиядәге вәзгыятькә фәнни анализ ясап, илдәге проблемаларның, икътисадый һәм социаль кыенлыкларның сәбәпләрен ачып бирә һәм Россиянең югары цивилизацияле дәүләтләр сафына басу юлларын да ачык күрсәтә. Ул Россия Федерациясенең киләчәге турында болай фикер йөртә. Социализмның һәм уңай, һәм кимчелекле яклары булды. Мәсәлән, тоталитарлык принциплары хәзерге чорда популяр түгел. Аеруча, 1930 еллардагы репрессияләр... Шуның өстенә, социализмның казанышларын үз күзләре белән күреп яшәгән кешеләр дөньядан китә бара, исәннәре җәмгыятебезнең киләчәген хәл итүдә актив катнаша алмый инде. Шунлыктан Россия җәмгыятенең яшь һәм урта буын вәкилләре социализмның фәкать «хәвефле» ягын гына күрә.

Ялган демократлар ягында торучы теоретиклар халыкны үзләре исәп тоткан кыргый капитализмга турыдан-туры өнди алмый, билгеле. Халык күреп тора: СССР заманында дәүләтебез иң абруйлы халыкара оешмалар тарафыннан дөньяда иң көчле икенче дәүләт дип саналса (беренче урында – АКШ), хәзерге заманда – чирек гасыр дәвам иткән «үзгәртеп кору»дан соң яңартылган Россиягә иң соңгы урыннарның берсе белән канәгатьләнергә туры килә. Ә инде «демократлар» тарафыннан макталган капитализмның барлык «сокландыргыч» сыйфатларын халык үз җилкәсендә җитәрлек татыды. Шунлыктан сәясәтчеләр, киләчәк турында сүз барганда, турыдын-туры капиталистик стройга әйләнеп кайтуны да пропагандалый алмый.

К.Т.Гыйззәтов илебездәге бүгенге вәзгыятьнең катлаулы, ә халык аңының берникадәр таркау булуын истә тотып, Россия җәмгыятенең киләчәген цивилизация үлчәме белән билгеләүне мәгъкуль күрә. Аның фикеренчә, хәзерге этапта илебезнең алдагы максатын цивилизацияле кыйммәтләр казанышына ирешү дип атау урынлы булыр иде. Шушы юнәлештә алга барган җәмгыять кенә милли идеологиягә ия булачак, дип саный ул. Бу җәмгыять, башкалар кебек, түбәндәге тармаклардан торачак: икътисадый җитештерү, социаль даирә, мәдәният (традицияләр, белем бирү, фән, сәнгать һ.б.), хокукый өлкә. Бүгенге

Россия һәр өлкәдә цивилизацияле илләрдән нык артта калып бара. Шунлыктан аны, алга киткән кайбер илләрнең тәҗрибәсенә таянып (шуның белән бергә Россиянең үзенчәлекләрен исәпкә алып), алар үрнәге нигезендә үзгәртеп корырга кирәк. Бу өлкәләрнең чагыштырмача камил, бүгенге көн таләпләренә җавап бирә алырлык үрнәкләре бар инде. Мәсәлән, яңа, алдынгы технологияләр нигезендә җитештерү буенча киләчәк җәмгыять өчен Германия, Франция, Япония, Кытай үрнәк була ала. Социаль сфера буенча Скандинавия илләре (Швеция, Норвегия, Финляндия), Бельгия белән Голландия муафыйк саналырлык, хокукый тармакны алсак, Англия тәҗрибәсе үрнәк була ала, халыкка белем бирү системасына элекке СССР казанышларын үрнәк итеп алырга мөмкин. Димәк, Россия үзенең киләчәген, шул исәптән милли идеологиясен, ә шушы бүгенге цивилизация үрнәкләре нигезендә төзи ала.

К.Т.Гыйззәтовның 40 еллык укытучылык тәҗрибәсе күп педагоглар өчен үрнәк булырлык. Аңа коллегалары белән аралашуда, студентларга белем һәм тәрбия бирүдә югары культуралылык һәм тыйнаклык хас иде.

Ул Казан вузларында, беренчеләрдән булып, фәлсәфә, эстетика кебек катлаулы курсларны татарча укыта башлый, үзләштерү өчен авыр материалларны студентларга гади телдә, аңлаешлы итеп җиткерү принцибы белән эш итә. Профессор К.Т.Гыйззәтов киң күңелле, игелекле, һәркемгә һәрчак ярдәм кулын суза торган кеше була. Аны меңләгән укучылары сагынып искә алалар.

Сәләтле кеше һәр эштә дә сәләтле була дигән әйтем бар. Бу гыйбарә язмабызның героена да бик туры килеп тора. Профессор Казбек Гыйззәтов, зур галим, күренекле педагог булу белән бергә, үзен әдәби иҗат өлкәсендә дә күрсәтә алды. Әтисенең иҗади сәләте аңа да бирелми калмаган, күрәсең. Ул Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» трилогиясе буенча күп серияле телевизион фильмга сценарий яза. Бу фильм 1980 елда экраннарда күрсәтелә. 1990 елларда К.Гыйззәтов рус телендә «В августе 91 года» дигән 8 серияле телевизион фильмга сценарий эшли. Монысы 1997 елда аерым китап булып басылып чыга.

Казбек Гыйззәтовның шәхси сыйфатлары турында сөйләгәндә, әтисенең истәлегенә, иҗатына аеруча зур ихтирам белән каравы турында әйтми мөмкин түгел. Ул аның иҗади мирасын саклау һәм бүгенге көн укучысына җиткерү юнәлешендә бинаһая зур эш башкара. Таҗи Гыйззәтнең тууына 80 ел тулу уңае белән аның әсәрләрен 4 томлык итеп бастырып чыгара. 2009 елда исә аның тырышлыгы белән Т.Гыйззәтнең 5 томлыгы дөнья күрә. Шулай ук «Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр. Хатлар. Бәхәсләр» [6] дип аталган зур күләмле хезмәт әзерли. Әтисенең бай иҗаты турында күп санлы мәкаләләр бастырып чыгара.

Данлыклы әтисе юлыннан тайпылышсыз барган Казбек Гыйззәтов үзе дә балалары өчен күркәм үрнәк булып яшәде. Ул үзенә лаеклы алмаш әзерләп калдырды. Аның кызлары Гүзәл белән Гөлназ аталарының һәм бабаларының бай рухи мирасын кадерләп саклыйлар һәм үстерәләр. Гүзәл Гыйззәтова Казан вузларының берсендә инглиз теле кафедрасын җитәкли. Ул, татар теле фразеологизмнарын инглиз теле чаралары белән чагыштырып өйрәнеп, докторлык диссертациясе яклады, профессор исеменә лаек булды. Гүзәл, инглиз теле белгече булуга карамастан, татар теле мәсьәләләре белән дә актив шөгыльләнә. Күптән түгел аның Сорбонна университетында татар телендәге сурәтләү чаралары турында ясаган фәнни доклады чит ил галимнәре тарафыннан югары бәя алды. Шулай итеп, Гыйззәтовларның мәдәниятне, мәгърифәтне, фәнне үстерү өлкәсендәге эшләре уңышлы дәвам иттерелә.

Күптән түгел профессор Таҗи улы Казбек Гыйззәтовның тууына 90 ел булды (ул бер еллар чамасы элек безнең арабыздан китеп барды инде). Аны якыннан белгән һәм хөрмәт иткән күп санлы хезмәттәшләре, укучылары бу олуг шәхесне зурлап искә алалар. Аталы-уллы Таҗетдин (Таҗи) һәм Казбек Гыйззәтовларның фидакарь тормышы, татарларның рухи үсеше өчен кылган изге гамәлләре халык күңелендә озак сакланыр.

**Әдәбият**


1. *Гыйззәтов К.Т.* Нәфасәт (Беренче китап). Казан: Мәгариф, 2004. 495 б.
2. *Гыйззәтов К.Т.* Нәфасәт (Икенче китап). Казан: Мәгариф, 2006. 480 б.
3. *Гиззатов К.Т.* Национальная идеология. М.: «Союз», 1999. 199 с.
4. *Гыйззәтов К.Т.* Философия (Беренче китап). Казан: Мәгариф, 2002. 447 б.
5. *Гыйззәтов К.Т.* Философия (Икенче китап). Казан:, Мәгариф, 2003. 407б.
6. *Гыйззәтов К.* Таҗи Гыйззәт. Казан: Мастер Лайн, 2000. 512 б.